**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ НОВОШЕШМИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
ул. Советская, д.80,
с. Новошешминск,423190

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЯҢА ЧИШМӘ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**
Совет урамы, 80,
Яңа Чишмә авылы, 423190

тел.: (8-84348) 2-31-00, факс: (8-84348) 2-20-22, chishma@tatar.ru

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

2024 елның «03» маеннан № 135

Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитетының аерым актларының үз көчләрен югалтуын тану турында

«Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнары һәм Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары арасында шәһәр төзелеше эшчәнлеге өлкәсендә вәкаләтләрне яңадан бүлү турында» 2023 елның 23 декабрендәге 131-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законы нигезендә 2024 елның 01 гыйнварыннан шәһәр төзелеше эшчәнлеге өлкәсендә вәкаләтләр Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгына (алга таба - Министрлык) тапшырылды, Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитеты карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитетының «Җир кишәрлеген яисә капиталь төзелеш объектын файдалануның шартлы рөхсәт ителгән төренә рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2021 елның 10 сентябрендәге 375 номерлы карары үз көчен югалткан дип танырга.

2. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитетының «Җир кишәрлегенең шәһәр төзелеше планын бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүләрнең административ регламентын раслау турында» 2021 елның 09 сентябрендәге 371 номерлы карары үз көчен югалткан дип танырга.

3. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитетының «Капиталь төзелеш объектларын рөхсәт ителгән төзүнең, реконструкцияләүнең иң чик параметрларыннан читкә тайпылуга рөхсәт бирү

буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2021 елның 29 июлендәге 303 номерлы карары үз көчен югалткан дип танырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең урынбасарына (инфраструктур үсеш буенча) йөкләргә.

Җитәкче Р.Р. Фасахов